**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 апрель № 215

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 ел, 27 ноябрь, ТРЗ-107 нче Татарстан Республикасы Законын, «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 ел, 20 ноябрь, ТРЗ-97 нче Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 24 декабрь, б-3044 нче, 2016 ел, 22 февраль, б-268 нче боерыклары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы, 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче, 2016 ел, 15 февраль, 95 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны финанслау күләмнәре*» юлын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны финанслау күләмнәре* | Программа буенча барлыгы – 724 877 503,9 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 368 802 768,1 мең сум, шулардан: |

| | |
|---|---|
| | беренче бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 5 913 104,1 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шул исәптән:<br>2013 ел – 4 485,2 мең сум,<br>2014 ел – 2 327 823,7 мең сум,<br>2015 ел – 1 634 350,2 мең сум,<br>2016 ел – 964 961,1 мең сум,<br>2017 ел – 964 961,1 мең сум,<br>2018 ел – 5 294,9 мең сум,<br>2019 ел – 5 512,0 мең сум,<br>2020 ел – 5 715,9 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 40 386 104,6 мең сум, шул исәптән:<br>2013 ел – 5 660 285,2 мең сум,<br>2014 ел – 4 299 389,0 мең сум,<br>2015 ел – 2 938 028,9 мең сум,<br>2016 ел – 3 392 558,5 мең сум,<br>2017 ел – 3 202 924,9 мең сум,<br>2018 ел – 6 765 529,9 мең сум,<br>2019 ел – 6 935 389,4 мең сум,<br>2020 ел – 7 191 998,8 мең сум;<br>беренче бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар – 151 365 776,3 мең сум, шул исәптән:<br>2013 ел – 15 943 700,6 мең сум,<br>2014 ел – 18 237 595,8 мең сум,<br>2015 ел – 19 485 895,2 мең сум,<br>2016 ел – 19 779 189,4 мең сум,<br>2017 ел – 21 368 065,4 мең сум,<br>2018 ел – 18 598 428,6 мең сум,<br>2019 ел – 18 849 315,1 мең сум,<br>2020 ел – 19 103 586,2 мең сум;<br>беренче бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган мәҗбүри медицина иминияте акчасы – 171 137 783,1 мең сум, шул исәптән:<br>2013 ел – 13 915 012,8 мең сум,<br>2014 ел – 17 892 587,8 мең сум,<br>2015 ел – 19 059 175,2 мең сум,<br>2016 ел – 19 942 028,1 мең сум,<br>2017 ел – 22 664 150,3 мең сум,<br>2018 ел – 24 635 948,8 мең сум,<br>2019 ел – 25 867 746,4 мең сум,<br>2020 ел – 27 161 133,7 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | өстәмә ихтыяҗ – 356 074 735,8 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән, шул исәптән:<br>2013 ел – 10 983 634,1 мең сум,<br>2014 ел – 25 264 061,7 мең сум,<br>2015 ел – 29 222 309,1 мең сум,<br>2016 ел – 36 491 481,2 мең сум,<br>2017 ел – 56 228 030,2 мең сум,<br>2018 ел – 59 668 390,1 мең сум,<br>2019 ел – 66 057 571,3 мең сум,<br>2020 ел – 72 159 258,1 мең сум.<br><br>1 нче ярдәмче программа. «Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру. Беренчел медицина-санитария ярдәмен үстерү»*<br>Барлыгы – 83 966 811,2 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 76 791 135,9 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 7 175 675,3 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>2 нче ярдәмче программа. «Махсуслаштырылган (шул исәптән югары технологияле) медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен камилләштерү»*<br>Барлыгы – 311 337 672,5 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 251 547 245,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 59 790 427,5 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>3 нче ярдәмче программа. «Дәүләт-шәхси партнерлыгын үстерү»*<br>Барлыгы – 4 122 077,3 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан чыганагы билгеләнгән – 4 122 077,3 мең сум (2013 елдан 2020елга кадәр).<br><br>4 нче ярдәмче программа. «Ана һәм бала сәламәтлеген саклау»*<br>Барлыгы – 8 365 451,0 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 4 971 097,4 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр); |

| | |
|---|---|
| | өстәмә ихтыяҗ – 3 394 353,6 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>5 нче ярдәмче программа. «Медицина тернәкләндерүен һәм шифаханә-курорт дәвалавын (шул исәптән балаларны) үстерү»*<br>Барлыгы – 6 727 990,7 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 2 081 480,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 4 646 510,0 мең сум, чыганагы билгеләнмәгән (2013 елдан 2020 елга кадәр).<br><br>6 нчы ярдәмче программа. «Паллиатив ярдәм күрсәтү, шул исәптән балаларга»*<br>Барлыгы – 297 589,8 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан чыганагы билгеләнгән – 297 589,8 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр).<br><br>7 нче ярдәмче программа. «Сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү»*<br>Барлыгы – 221 252 620,0 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр) (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шулардан:<br>чыганагы билгеләнгән – 14 915 372,3 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 206 337 247,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>8 нче ярдәмче программа. «Дарулар белән тәэмин итү системасын, шул исәптән амбулатория шартларында, камилләштерү»*<br>Барлыгы – 66 159 909,5 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 5 187 718,8 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 60 972 190,7 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>9 нчы ярдәмче программа. «Сәламәтлек саклауда мәгълүматлаштыруны үстерү»*<br>Барлыгы – 1 607 720,9 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), шулардан өстәмә ихтыяҗ – 1 607 720,9 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>10 нчы ярдәмче программа. «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру системасын камилләштерү»* |

| | |
|---|---|
| | Барлыгы – 19 884 478,0 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:<br>чыганагы билгеләнгән – 7 733 867,9 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);<br>өстәмә ихтыяҗ – 12 150 610,1 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.<br><br>11 нче ярдәмче программа. «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү»*<br>Барлыгы – 1 155 183,0 мең сум, шулардан чыганагы билгеләнгән – 1 155 183,0 мең сум (2014 елдан 2016 елга кадәр)»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа буенча барлыгы – 724 877 503,9 мең сум (өстәмә ихтыяҗны исәпкә алып), шул исәптән:

чыганагы билгеләнгән – 368 802 768,1 мең сум, шулардан:

беренче бәяләү буенча федераль бюджет акчасы – 5 913 104,1 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

беренче бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 40 386 104,6 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

беренче бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар – 151 365 776,3 мең сум;

беренче бәяләү буенча мәҗбүри медицина иминияте акчасы – 171 137 783,1 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр);

өстәмә ихтыяҗ – 356 074 735,8 мең сум (2013 елдан 2020 елга кадәр), чыганагы билгеләнмәгән.

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү бюджет циклы кысаларында ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

Программаның «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» дигән 11 нче ярдәмче программада (алга таба – 11 нче ярдәмче программа):

11 нче ярдәмче программа паспортының «Дәүләт заказчысы (дәүләт заказчысы-яраштыручысы)», «Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр», «Ярдәмче программаны җаваплы үтәүчеләр» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы, ярдәмче программаның яраштыручысы, төп эшләүчесе | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы |
| Җаваплы башкаручы, бюджет һәм бюджеттан тыш акчаларны төп алучы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

11 нче ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны финанслар белән тәэмин итү күләмнәре | Барлыгы – 1 155 183,0 мең сум «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясендә 100 койкага исәпләнгән перинаталь үзәк төзелеше» объекты буенча, шул исәптән:<br>беренче бәяләү буенча җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы –2015 елда 615 379,7 мең сум;<br>беренче бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 539 803,3 мең сум, шулардан төзелеш-монтажлау эшләренә – 506 157,3 мең сум, проектлау-тикшеренү эшләренә – 33 646,0 мең сум, шул исәптән:<br>2014 елда – 0 сум;<br>2015 елда – 107 558,4 мең сум;<br>2016 елда – 432 244,9 мең сум»; |

11 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Барлыгы – 1 155 183,0 мең сум, шулардан:

Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды бюджетыннан субсидияләр – 615 379,7 мең сум, шул исәптән:

2014 елда – 0 сум;

2015 елда – 615 379,7 мең сум;

2016 елда – 0 сум;

беренче бәяләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы– 539 803,3 мең сум, шул исәптән:

2014 елда – 0 сум;

2015 елда – 107 558,4 тыс мең сум;

2016 елда – 432 244,9 мең сум.

Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды субсидиясе һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән ярдәмче программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү бюджет циклы кысаларында ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү чираттагы финанс елына һәм план чорына Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды (алга таба – ММИФФ) бюджеты турында федераль законда каралган ММИФФ бюджеты акчасы, шулай ук чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүленгән бюджет ассигнованияләре хисабына гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүленгән ММИФФ акчасы ММИФФ бюджетыннан Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 18 октябрь, 2077-б номерлы боерыгында билгеләнгән күләмдә субсидияләр рәвешендә бирелә.

ММИФФ субсидиясе һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән ярдәмче программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү бюджет циклы кысаларында ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасы чараларын финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын тормышка ашыру чаралары турында» 2015 ел, 1 июнь, 395 нче карары (алга таба – 2015 ел, 1 июнь, 395 нче карар) белән билгеләнде.

Ярдәмче программаны еллар буенча финанслау күләмнәре Программага 1 нче кушымтада китерелде.»;

11 нче ярдәмче программаның IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмнары

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт заказчысы – яраштыручысы (алга таба – ярдәмче программаның яраштыручысы) буларак:

ярдәмче программаны эшләү, тормышка ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү процессында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-

коммуналь хуҗалык министрлыгы белән багланышларны тәэмин итә;

ярдәмче программага 1 нче кушымтада китерелгән перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү эшләрен башкаруның челтәр графигы (алга таба – челтәр графигы) нигезендә ярдәмче программаны тормышка ашыруны яраштыру һәм мониторинглауны гамәлгә ашыра;

перинаталь үзәкне медицина хезмәткәрләре беләрн тәэмин итә;

кирәк булган очракта ярдәмче программага билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертә.

Ярдәмче программаның җаваплы башкаручысы:

катгый рәвештә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә төзелә торган дәүләт контрактлары нигезендә ярдәмче программа чараларын тормышка ашыра;

ярдәмче программа чарасы бәясенең нигезле булуы өчен җавап тота;

перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү, ярдәмче программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчаны максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өлешендә ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен җавап тота;

2015 ел, 1 июнь, 395 нче карарда билгеләнгән тәртиптә хисаплылыкны үз вакытында тапшырган һәм аның дөреслеге өчен җавап тота;

яңа перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү барышын тикшерүне гамәлгә ашыра;

ярдәмче программаның яраштыручысына ярдәмче программага үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр җибәрә (зарур булган очракта).

«2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын тормышка ашыру турында хисаплылык формалаштыру һәм аны тапшыру тәртибе 2015 ел, 1 июнь, 395 нче карары белән билгеләнде.»;

11 нче ярдәмче программаның «Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм ярдәмче программа чаралары буенча финанслау

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме, мең сум | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | | 2015 ел | 2016 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Максат: Татарстан Республикасында хатын-кызларга һәм балаларга күрсәтелә торган медицина ярдәменең һәркем файдалана алу дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, шул исәптән аналар үлеме һәм сабыйлар үлеме күрсәткечләрен киметү | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясендә 100 койкага исәпләнгән перинаталь үзәк проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү | Татарстан Республикасында йөкле хатын-кызларга һәм яңа туган балаларга нәтиҗәле өч дәрәҗәле ярдәм күрсәтү системасын формалаштыруны тәгәлләү максатыннан чыгып, яңа перинаталь үзәк проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү | ТР ССМ, ТР ТАhТКХМ | 2014 – 2016 еллар | аналар үлеме,<br><br>100 мең исән туган очракка | 10,6 | 10,5 | 10,4 | 10,3 | 8,8 | билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет | 615 379,7 | - |
| | | | | | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты | 107 558,4 | 432 244,9 |
| Перинаталь үзәктә медицина ярдәме күрсәтәчәк медицина хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү | Перинаталь үзәктә медицина ярдәме күрсәтәчәк медицина хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү | ТР ССМ | 2014 – 2016 еллар | сабыйлар үлеме, 100 мең исән туучыга очрак | 6,4 | 6,3 | 6,2 | 6,1 | 6,0 | | | |
| Татарстан Республикасында йөкле хатын-кызларга һәм яңа туган балаларга нәтиҗәле өч дәрәҗәле ярдәм күрсәтү системасын формалаштыруны тәгәлләү | Эшнең күчмә формалары белән акушерлык дистанцион консультация үзәкләре эшен камилләштерү | ТР ССМ | 2014 – 2016 еллар | перинаталь үзәкләрдә вакытыннан алда бала тапкан, җиңеләйгән хатын-кызлар өлеше, % | 50,0 | 52,0 | 55,0 | 60,0 | 70,0 | | | |
| | Акушерлык стационарлары челтәрләрен реструктурлаштыру һәм койка фондын файдалануны рациональләштерү | ТР ССМ | 2014 – 2016 еллар | яшьли неонаталь үлем күрсәткече, 100 мең исән туган очракка | 3,0 | 3,0 | 2,9 | 2,85 | 2,8 | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Заманча медицина технологияләрен кертү | ТР ССМ | 2014 – 2016 еллар | туганда бик кечкенә һәм экстремаль авырлыкта булган балаларның исән калу очрагы, перинаталь үзәкләрдә,% | 65,3 | 66,5 | 70,0 | 73,0 | 75,0»; | | | |
| | Оештыру-методик һәм клиника-экспертиза эшен камилләштерү | ТР ССМ | 2014 – 2016 ел | | | | | | | | | |

Программага теркәлгән 1 нче кушымтада 277 – 289 юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «11 нче ярдәмче программа. «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» | 1 155 183,0 | 0,0 | 0,0 | 722 938,1 | 432 244,9 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет | 615 379,7 | 0,0 | 0,0 | 615 379,7 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| ММИ фондына бирелә торган бюджетара трансфертларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджеты, шул исәптән: | 539 803,3 | 0,0 | 0,0 | 107 558,4 | 432 244,9 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджеты | 539 803,3 | 0,0 | 0,0 | 107 558,4 | 432 244,9 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан ТР ММИТ фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Мәҗбүри медицина иминияте | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| БАРЛЫГЫ | 368 802 768,1 | 35 523 483,8 | 42 757 396,3 | 43 117 449,5 | 44 078 737,1 | 48 200 101,7 | 50 005 202,2 | 51 657 962,9 | 53 462 434,6 |
| Билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет | 5 913 104,1 | 4 485,2 | 2 327 823,7 | 1 634 350,2 | 964 961,1 | 964 961,1 | 5 294,9 | 5 512,0 | 5 715,9 |
| ММИ фондына бирелә торган бюджетара трансфертларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджеты, шул исәптән: | 191 751 880,9 | 21 603 985,8 | 22 536 984,8 | 22 423 924,1 | 23 171 747,9 | 24 570 990,3 | 25 363 958,5 | 25 784 704,5 | 26 295 585,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 40 386 104,6 | 5 660 285,2 | 4 299 389,0 | 2 938 028,9 | 3 392 558,5 | 3 202 924,9 | 6 765 529,9 | 6 935 389,4 | 7 191 998,8 |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан ТР ММИТ фондына бирелә торган бюджетара трансфертлар, шул исәптән: | 151 365 776,3 | 15 943 700,6 | 18 237 595,8 | 19 485 895,2 | 19 779 189,4 | 21 368 065,4 | 18 598 428,6 | 18 849 315,1 | 19 103 586,2 |
| Эшләми торган халыкны мәҗбүри ме- | 89 274 779,4 | 7 913 419,0 | 9 896 017,3 | 12 931 462,9 | 12 931 462,9 | 13 487 515,8 | 10 561 850,6 | 10 704 326,5 | 10 848 724,4 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| дицина иминият-ләштерүенә акча | | | | | | | | | |
| Мәҗбүри медицина иминияте | 171 137 783,1 | 13 915 012,8 | 17 892 587,8 | 19 059 175,2 | 19 942 028,1 | 22 664 150,3 | 24 635 948,8 | 25 867 746,4 | 27 161 133,7». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 15 февраль, 95 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков